**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй , Иске Арыш, Керәшен Казысы авыл торак пунктларында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

2022 елның 28 ноябре

№1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй , Иске Арыш,Керэшен Казысы авылы торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- кышкы чорда Балыклы-Чүкәй авылы җирлегендә юлларны карап торуга
- Керәшен Казысы авылында Королева урамынын бер олешенэ,Иске Арыш авылында Вазитов урамына юлга вак таш җәю өчен
- су кутэру насосы алу очен Керәшен Казысы һәм Иске Арыш авылларында
- Балыклы-Чүкәй авылында чуплекләрне чистарту очен

соравы (мәсьәләсе) буенча 2022 елның 23,24,25 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенының сайлау хокукына ия катнашучылары исемлегенә 517 кеше кертелде, тавыш бирүдә җыенның 237 кешесе катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен 237 җыенда катнашучы тавыш биргән;

“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш биргән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй, Иске Арыш, Керәшен Казысы авыл торак пунктларында гражданнар җыеннарын булды дип, гражданнар җыеннары нәтиҗәләрен **дөрес** дип танырга.

2. “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй, Иске Арыш,Керэшен Казысы авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- кышкы чорда Балыклы-Чүкәй авылы җирлегендә юлларны карап торуга
- Керәшен Казысы авылында Королева урамынын бер олешенэ,Иске Арыш авылында Вазитов урамына юлга вак таш җәю өчен
-су кутэру насосы алу очен Керәшен Казысы һәм Иске Арыш авылларында
- Балыклы-Чүкәй авылында чуплекләрне чистарту очен

соравы (мәсьәләсе) буенча карарны **кабул ителде** дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урамы, 8нче йорт; Иске Арыш авылы,Үзәк урамы,23 В йорт; Керәшен Казысы авылы, Титов урамы, 11Б йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге башлыгы: И.С.Мазитов